Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Кугәрчен авыл җирлеге Советы

**КАРАР № XIII**

Күгэрчен авылы 2019 елның 10 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күгэрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күгэрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күгэрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 86,87,88 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгэрчен авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгэрчен авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 апрелендәге 9 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күгэрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгэрчен авыл җирлеге Советының 2016 елның 1 декабрендәге 20 номерлы, 2017 елның 25 июлендәге VII, 2018 елның 27 апрелендәге IV, 2018 елның 12 октябрендәге IX номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә юлларга.

3. Карарны дәүләт теркәвеннән соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгэрчен авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Күгэрчен авылы, Совет урамы , 62А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күгәрчен авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 88 маддәсе 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Күгәрчен авыл
җирлеге Советының 2019
елның 10 октябрендәге XIII
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күгәрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күгәрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 5 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 20 пункт белән тулыландырырга:
“Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү”;

2) 6 маддәнең 1 пункты 13 пунктчасында “даими яшәүче караучысыз хайваннарны тотып алу һәм карау буенча чараларның” сүзләрен “даими яшәүче иясез хайваннар белән мөгамәлә итү буенча эшчәнлекнең” сүзләре белән алмаштырырга;

3) 22 маддәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсендә күздә тотылган гражданнар җыены анда торак пунктның яки җирлекнең сайлау хокукына ия булган яшәүчеләренең яртысыннан артыгы катнашканда вәкаләтле. Әлеге торак пункттагы сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булуына мөмкинлек булмаган очракта гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә этаплап гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән соң бер айдан артмаган срокта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә үткәрелә. Шуның белән бергә гражданнар җыенында элек катнашкан затлар шуннан соңгы этаплардагы тавыш бирүдә катнашмыйлар. Гражданнар җыены карары җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.”;

4) 29 маддәнең 1 пункты “10” цифрын “7” цифры белән алмаштырырга;

5) 30 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“6. Җирлек Советы депутаты 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазифаларны (йөкләмәләрне) башкарырга тиеш. Совет депутатының вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы

Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазифаларын биләүчеләрнең һәм бүтән затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне (вазифаларны) башкармау очрагында, әгәр башкасы 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылмаган булса, вакытыннан алда туктатыла;

6) 30 маддәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8.Әлеге маддәнең 7 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазифаларын биләүчеләрнең һәм бүтән затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне башкармау фактлары ачылганда (беленгәндә), Татарстан Республикасы Президенты тиешле карарны кабул итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка Совет депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алдан туктату яки күрсәтелгән затка карата башка җаваплылык чарасы куллану турында белдерү белән мөрәҗәгать итә.”;

7) 30 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 8.1, 8.2 пунктлары белән тулыландырырга:

“8.1. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырган җирле үзидарә депутатына, әгәр әлеге мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазифалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органындагы вазифасыннан азат итү;

3) вәкаләтләр вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазифалар биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләр үтәүне тыю.”;

8.2. Депутатка карата әлеге матдәнең 8.1 пунктында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә үзидарәлек хокукый акты белән тәгаенләнә.";

8) 43 маддәнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.Җирлек башлыгы 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт вазифаларын биләүчеләрнең һәм бүтән затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында" 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, йөкләмәләрне (вазифаларны) башкарырга тиеш;

9) 33 маддәнең 1 пункты 24 пунктчасын, 49 маддәнең 1 пункты 3 пунктчасының 7 абзацын көчен югалткан дип танырга;

10) 49 маддәнең 1 пункты 7 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү";

11) 49 маддәнең 2 пунктының 13 абзацында "даими яшәүче караучысыз хайваннарны тотып алу һәм карау буенча чараларның" сүзләрен "даими яшәүче иясез хайваннар белән мөгамәлә итү буенча эшчәнлекнең" сүзләре белән алмаштырырга;

12) 63 маддәдә:

а)1 пунктның 2 пунктчасын ", әгәр федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса" сүзләре белән тулыландырырга;

б)түбәндәге эчтәлектәге 3 һәм 4 пунктлары белән тулыландырырга:

"3. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырган җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына карата, әгәр әлеге мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы җирле үзидарәнең сайланулы органында вазифалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазифасыннан азат итү;

3) вәкаләтләр вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы җирле үзидарәнең сайланулы органында вазифалар биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.”;

“4. җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына карата әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә үзидарәлек хокукый акты белән тәгаенләнә.”.

13) 85 маддәнең 1 пунктында “Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм башка норматив” сүзләрен "нигезләмәләрнең" сүзе белән алмаштырырга, ",ачык норматив йөкләмәләрне һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга бүтән түләүләр буенча йөкләмәләрне шарт белән чикләүче хокукый актларның, шулай ук бюджеттан средстволар бирү турында дәүләт (үзидарәлек) контрактларының, шартнамәләренең (килешүләренең) шартларын үтәүнең” сүзләре белән тулыландырырга;

14) ) 85 маддәнең 2 пунктында “бюджет хокукый мөнәсәбәтләре өлкәсендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 85 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Эчке үзидарәлек финанс контроле җирлек Башкарма комитеты органнары (вазифаи затлары) булган үзидарәлек финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.”;

16) 88 маддәнең 2 пунктының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.Җирлек Уставы (Низамнамәсе), әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы карары аларны дәүләт теркәвеннән соң
http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының “Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары”порталында рәсми төстә игълан ителергә (халыкка белдерелергә) тиеш (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басма сыйфатында теркәлү: Эл № ФС77-72471 05.03.2018)”.